| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>ШАРЛИАРЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| **1 ноябрь 2024 ел** | **№ 101** |

Сарман муниципаль районының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 18 маендагы 130 номерлы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Шәрләрәмә авыл җирлеге советы карар итте:

1.Сарман муниципаль районының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында» Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы 130 номерлы 18 май 2020 елгы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 9 пунктының 6 абзацында «түләнергә тиешле сумманы исәпләгән көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяның 9 пунктынына түбәндәге эчтәлекле 7 абзац өстәргә:

«бюджетка түләүләр буенча дебитор бурычларын, пенялар һәм штрафлар буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгели;»;

3) 9 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«туристлык салымы - 100 процент норматив буенча.»;

2. Әлеге карарның 1 пунктның 2 пунктчасы 01.01.2025 елдан үз көченә керә..

3. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда әлеге карарны игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге
Совет рәисе Н.Н.Хуҗина